| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.03.2020 ел Баулы шәһәре №53

Баулы муниципаль районының
Кызылъяр авылы Совет, Сабирҗанов,
Дуслык, Т. З. Шакиров урамнарында,
Васькино-Туйралы авылы Яңа урамыда,
Дубовка авылы Чишмә урамында газ
белән тәэмин итү схемалары проектлары
буенча халык алдында фикер
алышуны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 10 сентябрендәге «Торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру буенча төбәкара һәм региональ программаларны эшләү һәм тормышка ашыру тәртибе турында» 903 номерлы карары нигезендә (2019 елның 21 февралендәге 179 номерлы карары редакциясендә), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын газлаштыру буенча чаралар планын формалаштыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 22 августындагы 693нче карары белән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 1нче һәм 2нче кушымталар нигезендә Баулы муниципаль районының Кызылъяр авылы Совет, Сабирҗанов, Дкслык, Т. З. Шакиров урамнарында, Васькино-Туйралы авылы Яңа урамыда, Дубовка авылы Чишмә урамында газ белән тәэмин итү схемалары проектлары буенча халык алдында фикер алышуны билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. ачык тыңлаулыр үткәрү датасын - әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы

муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) басылып чыкканнан соң 30 көн узгач;

2.2. ачык тыңлаулар үткәрү урыннары:

- Баулы муниципаль районы Кызыл Яр авыл җирлеге башкарма комитеты, адресы: ТР, Баулы районы, Кызылъяр авылы, Гагарин урамы, 2а йорты;

- Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге башкарма комитеты, адресы: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Потап-Томбарлы авылы, Совет урамы, 20;

2.3. фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, ачык тыңлауларды чыгыш ясау хокукы белән катнашуга гаризалар түбәндәге адреслар буенча бирелә:

ТР, Баулы районы, Кызылъяр авылы, Гагарин ур., 2а йорт (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр);

- ТР, Баулы районы, Потап-Томбарлы авылы, Совет урамы, 20нче йорт (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр).

3. Фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы затлар итеп Баулы муниципаль районы Кызылъяр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Э.А. Сафинаны (килешү буенча) һәм Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе С. А. Козлованы (килешү буенча) (алга таба - Башкарма комитет җитәкчеләре) билгеләргә.

4. Башкарма комитет җитәкчеләренә киңәш итәргә:

- ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү буенча законнар, муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәргә;

- кызыксынган затларга ачык тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирергә.

5. №3 кушымта нигезендә, кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.


7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 20 мартындагы
53 номерлы карарына
1нче кушымта


Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлеге Кызылъяр авылы Совет, Сабирҗанов, Дуслык, Т. З. Шакиров урамнарында белән тәэмин итү схемалары проекты




Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
эшләр белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 20 мартындагы
53 номерлы карарына
2нче кушымта

Баулы муниципаль районының Потап-Томбарлы авыл җирлегенең Васькино-Туйралы авылы Яңа урамыда, Дубовка авылы Чишмә урамында газ белән тәэмин итү схемалары проекты




Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
эшләр белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 20 мартындагы
53 номерлы карарына
3нче кушымта

Кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Вәлиев И.Р. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктуратура үсеше буенча урынбасары; |
| Адамова Р.А. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы; |
| Хәсиятуллина Р.И. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы; |
| Каһиров Р.А. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы; |
| Хәбипов Р.Н. | - | «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Бугульмагаз» эксплуатация-җитештерү идарәсенең Баулы район газ хезмәте начальнигы (килешү буенча); |
| Сафина Э.А. | - | Баулы муниципаль районы Кызылъяр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Козлова С.А. | - | Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
эшләр белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов